Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге Советының егерме бишенче утырышы

Питрәч авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

14 декабрь, 2023 ел № 90

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турында нигезләмәнең үз көчен югалтуын тану хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы кодексының $16^{1}$ статьясы нигезендә Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге советы муниципаль хезмәт турында карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) идарәсендә бушлай катнашуга яисә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советының 2017 елның 18 августындагы 67 номерлы карары (Советның 2019 елның 5 апрелендәге 121 номерлы, 2020 елның 3 мартындагы 155 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләр белән) белән расланган идарәнең коллегиаль органнары составына керүенә рөхсәт алу тәртибе турында нигезләмәне көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы И.М. Кашапов